ГЛАВА ЛЕШЕВ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛӘШӘҮ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«06» нчы июнь 2023 ел №2

**Хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннарны билгеләү турында һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терлекләрне хуҗалардан башка кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

ФАП территориясе;
мәктәп территориясе;
балалар бакчасы территориясе;
парклар, скверлар территориясе;
балалар уен мәйданчыклары территориясе.

2.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Хабибуллин Илфат Заһит улын - хуҗалардан башка терлекләрне элекке яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Сарман районы Ләшәү Тамак авылы Механизаторлар урамы, 1 а, Тубән Ләшәү авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы 38а., Сарайлы авылы, М.Җәлил урамы, 39а адреслары буенча урнашкан махсус җиһазланган мәгълүмати стендларда бастырырга һәм Сарман муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында (https://sarmanovo. tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (порталда)https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Башлыгы И.З.Хабибуллин